■ Хәзрәт вәгазе

# БАЛА ТӘРБИЯЛӘҮ

## Балаларыбызга Аллаһ (җ.җ.) һәм Пәйгамбәр (с.г.в.)не ничек аңлата алабыз?

Әни баласының бәләкәй урлауларына игътибар бирмичә: ”Ул әле бала”, - дип әйтә. Ләкин бу баланың киләчәктә эшләячәк зур явызлыкларның нигезен барлыкка китерә. Сез дә балаларыгызны нинди нигез белән үстергәнегезне уйлагыз. Бәлки, бер урында хата ясыйсыздыр.

Балалар язылмаган CD яки аудио кассета кебек. Бер тавышны яздырган вакытта магнитофоныбыз ничек тыштан ишетелгән тавышларның бөтенесен язып бара, шулай ук балаларыбыз да күргән һәм ишеткән бөтен нәрсәләрне исләрендә калдырып баралар. Әгәр сез балаларыгызга Аллаһ һәм Пәйгамбәребез (с.г.в.)не аңлатырга телисез икән, бала туганнан ук, иң башта үз тормышларыгызны тикшереп, ямьсез күренгән яки җитми калган якларыгызны төзәтергә тиешсез. Югыйсә бала сезнең ничек яшәгәнегезне күреп үскәннән соң, аны үзегез эшләгәннән башкача тәрбияләвегез мөмкин булмас.

Шулай булгач баланы тәрбияләүдә нинди юл белән барырга кирәк? Икенчедән, балаларыбызга телевизор аркылы тыштан килгән тәрбиянең тәэсире ничек булыр,

Бу сорауга дүрт яшендәге Әхмәтнең бабасы белән мәчеткә барып күргәннәреннән нинди рәвештә тәэсирләнгәне безгә яхшы җавап булырга мөмкин.

### Патша таҗы кигән намаз укыта

Аның исеме Әхмәт. Дүрт яшенә баскан. Бик хәрәкәтле матур бер малай. Бабасына барган бер көндә, ул аның кулыннан тотып мәчеткә алып барган иде. Әхмәт өчен мәчеткә бару бик аерым бер хис булды. Өйгә кайткач йөзендәге куанычы бөтен кеше тарафыннан күренеп тора иде... Әнисе аңардан мәчеттә нәрсә күргәнен сорагач, ул шуларны аңлаткан иде: ”Әни, мәчеттә бер патша бар. Өстендә ак тукымадан тегегән матур кием. Намаз укытсын өчен үзенә аерым бер урын ясаганнар. Ул нәрсә эшәгән булса, без дә аңа ияреп шуны эшләдек. Ул бөгелде - без бөгелдек, ял ятты - без дә яттык, ул ике ягына карады - без дә карадык. Үзенең башында таҗы да бар иде”.

Өй халкы Әхмәтнең бу сүзләренә бик аптырадылар. Чөнки ул имамны патшага, киемнәрен дә аның киеменә, башындагы чалманы таҗга охшаткан иде. Дүрт яшендәге бер бала бу кадәр мәгълүматны каян алганына әни-этиләре бик аптырасалар да, Әхмәтнең көненә ике сәгать телевизор караганы аларның исләренә берничек тә төшмәде. Әхмәт һәркөнне ике сәгать мультикпликацион фильм карау белән үзенә шулкадәр мәгълүмат җыйган, һәм шуның аркасында да имамны патшага охшаткан иде. Димәк, өйдә мәчет, имам, михраб, менбәр, чалма, чапан кебек сүзләр кулланылмаган өчен, ул бөтен боларны үзенчә аңлаган.

### Иярәшүгә әйләнергә тиеш

Әни-эти өч яшендәге малайларына һәркөнне әкият сөйләүне һәм дога укуны үзләренә гадәт итеп кертkәннәр иде. Бәләкәй Хәсән әкиятне әтисеннән тыңлаганнан соң, әнисе белән дога кабатлый иде. Ләкин бер төнне әни, көндез бик арыганлыктан, улына дога кылдыруны онытkан иде. Хәсәннең: ”Әни, бүген дога кылмадык”, дигән сүзләре яшь әнинең күзләреннән яшьләрнең агуына сәбәп булды. Әни сөйләде, бала кабатлады: ”Яттым, Аллаһ, уят мине, нур эченә керт мине, әгәр иртән тора алмасам, Коръән һәм иман белән күндер мине”. Сез дә бу дога белән балаларыгызны йоклата аласыз.

### *Сәбәпләрне кулланыгыз*

Аллаһны аңлату мәсьәләсендә яки Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең кем икәнен аңлатуда һәр мөмкинчелекне куллану бик мөһим һәм кирәк. Ләкин моның белән баланы биздерә дә күрмәгез. Мәçәлән, шул юлны куллана аласыз. Мәхмүтнең Мостафа исемендә бик яраткан абыйсы бар иде. 3 яшендәге Мәхмүтне абыйсы белән уйнау бик куандыра иде. Әнисе кайбер вакытларда аңа Аллаһның исемен өйрәтү максаты белән: ”Мәхмүт, сине кем яратты?” - дип сораган вакытта ул: ”Аллаһ яратты”, - дип җавап бирә иде. Мәхмүттән Пәйгамбәребез (с.г.в.) соралган вакытта, әгәр аның исенә төшмәсә: ”Синең абыеңның исеме ничек?” - дигән рәвештә сорау белән Мостафа исеме ”Пәйгамбәребез кем?” соравына җавап була иде.

### Әни булу

Урамга яңа гына йөри башлаган беләкәй бала беркөнне әнисенә бео йомырка китерә. Шәфкате акылын җинеп алган әни баласын тиз генә күтәреп күкрәгенә кыса һәм: ”Кара син, минем улым үскән икән, әнисен карый башлаган”, - дигән сүзләр белән баласын маңгаеннан үбә.

Әнисенең күкрәгенә кысып үбүе баланы бик куандыра һәм берничә көннән соң кулына бер тавык тотып өйгә керә. Шулай булып башка бер көнне бер кәҗә, шуннан бер сарык дигәндә бу бала угры булып үсә. Мәхәллә арасында иң зур карак дигән исем белән мәшһүр булып китү бик кыен булмады. Аны инде беркем дә туктата алмаслык дәрәҗәгә килеп җитте. Теләгән өйгә керә, кайбер вакытта, беркем белмәсен өчен, хуҗаларны үтереп тә китә иде. Шуның өчен милиция аны эзли башлады. Беркөнне бер кешене үтергән аркасында аны тоттылар. Суд булып үтте. Нәтиҗәдә бу кешене үтерергә карар чыгарылды.

Бу баланың әнисе бик нык елап, баласы хакында чыгарылган карарга риза булмаганын күрсәтә иде.

Хакимнәр бу кешегә: ”Әниеңә әйтер сүзең бармы, Моннан соң аны күрмәячәксең”, - диделәр.

Гаепле кеше: ”Мин гомеремнең азагына әниемнең телен үбәргә телим”, - дип теләген аңлатты. Әнисен чакырдылар. Бала әнисенең телен үбәр урынына нык итеп тешләп, өзеп ташлады. Мәхкәмә залында бик зур тавыш булды. Бер яклап теле өзелгән әнинең ачулы тавышы, икенче яклап хакимнәрнең гаепле кешене тиргәү сүзләре, башка яклап гаепле кешенең үзен аклый торган сүзләре...

- Кара син шул әдәпсезне, бүгенгә кадәр эшләгән хаталары җитмәгән сыман хәзер дә әнисенең телен өзеп ташлады...

- Хәерсыз бала, телемне тешләп өзде!

- Юк, мин гаепле түгел! Бәлки тормышым буена эшләгән иң дөрес эшем шулдыр.

-Сөйләтмәгез шул әдәпсезне. Әле дә үзен гаепсез дип саный.

- Зинһар өчен, миңа сөйләргә мөмкинчелек бирегез. Сезгә бер нәрсәне ачыклыйсым килә.

- Әйт, тагы нәрсә әйтергә телисең?

- Мин бала булган вакытта күршенең сараеннан бер йомырка урлап алып килгән идем. Ләкин әнием минем бу йомырканы каян алганымны сорамады. Хәтта мине кочаклап күкрәгенә кысты һәм төрле сүзләр белән куанычын миңа күрсәтте. Мин урлауның нәрсә икәнен һәм нәтиҗәдә кая алып барачагын белми идем. Менә бүгенге көндә хакымда үлем карары чыкты. Мин шулкадәр эшләгән яман эшләремнең җәзасын тормышымны югалту белән күрәм. Ә әнием телен югалту белән...

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Зөлхизә 2010 миләди йыл**

**1431 һижри йыл.**

| Зөлхиҙә | Аҙна көндәре | Ноябрь | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сығыа | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Йәкшәмбе | 7 | 7.01 | 8.31 | 13.30 | 15.59 | 17.29 | 18.59 |
| 2 | Дүшәмбе | 8 | 7.03 | 8.33 | 13.30 | 15.57 | 17.27 | 18.57 |
| 3 | Шишәмбе | 9 | 7.05 | 8.35 | 13.30 | 15.55 | 17.25 | 18.55 |
| 4 | Шаршамбы | 10 | 7.07 | 8.37 | 13.30 | 15.53 | 17.23 | 18.53 |
| 5 | Кесе йома | 11 | 7.09 | 8.39 | 13.30 | 15.51 | 17.21 | 18.51 |
| 6 | Йома | 12 | 7.11 | 8.41 | 13.30 | 15.49 | 17.19 | 18.49 |
| 7 | Шәмбе | 13 | 7.13 | 8.43 | 13.30 | 15.48 | 17.18 | 18.48 |
| 8 | Йәкшәмбе | 14 | 7.15 | 8.45 | 13.30 | 15.46 | 17.16 | 18.46 |
| 9 | Дүшәмбе | 15 | 7.17 | 8.47 | 13.30 | 15.44 | 17.14 | 18.44 |
| 10 | Шишәмбе | 16 | 7.19 | 8.49 | 13.30 | 15.43 | 17.13 | 18.43 |
| 11 | Шаршамбы | 17 | 7.21 | 8.51 | 13.30 | 15.41 | 17.11 | 18.41 |
| 12 | Кесе йома | 18 | 7.23 | 8.53 | 13.30 | 15.40 | 17.10 | 18.40 |
| 13 | Йома | 19 | 7.24 | 8.54 | 13.30 | 15.38 | 17.08 | 18.38 |
| 14 | Шәмбе | 20 | 7.26 | 8.56 | 13.30 | 15.37 | 17.07 | 18.37 |
| 15 | Йәкшәмбе | 21 | 7.28 | 8.58 | 13.30 | 15.36 | 17.06 | 18.36 |
| 16 | Дүшәмбе | 22 | 7.30 | 9.00 | 13.30 | 15.34 | 17.04 | 18.34 |
| 17 | Шишәмбе | 23 | 7.32 | 9.02 | 13.30 | 15.33 | 17.03 | 18.33 |
| 18 | Шаршамбы | 24 | 7.34 | 9.04 | 13.30 | 15.32 | 17.02 | 18.32 |
| 19 | Кесе йома | 25 | 7.35 | 9.05 | 13.30 | 15.31 | 17.01 | 18.31 |
| 20 | Йома | 26 | 7.37 | 9.07 | 13.30 | 15.29 | 16.59 | 18.29 |
| 21 | Шәмбе | 27 | 7.39 | 9.09 | 13.30 | 15.28 | 16.58 | 18.28 |
| 22 | Йәкшәмбе | 28 | 7.41 | 9.11 | 13.30 | 15.27 | 16.57 | 18.27 |
| 23 | Дүшәмбе | 29 | 7.42 | 9.12 | 13.30 | 15.26 | 16.56 | 18.26 |
| 24 | Шишәмбе | 30 | 7.44 | 9.14 | 13.30 | 15.25 | 16.55 | 18.25 |
| 25 | Шаршамбы | 1 | 7.46 | 9.16 | 13.30 | 15.25 | 16.55 | 18.25 |
| 26 | Кесе йома | 2 | 7.47 | 9.17 | 13.30 | 15.24 | 16.54 | 18.24 |
| 27 | Йома | 3 | 7.49 | 9.19 | 13.30 | 15.23 | 16.53 | 18.23 |
| 28 | Шәмбе | 4 | 7.50 | 9.20 | 13.30 | 15.22 | 16.52 | 18.22 |
| 29 | Йәкшәмбе | 5 | 7.52 | 9.22 | 13.30 | 15.22 | 16.52 | 18.22 |
| 30 | Дүшәмбе | 6 | 7.53 | 9.23 | 13.30 | 15.21 | 16.51 | 18.21 |

## КРОССВОРД



1. Мәккә мөшрикләре табынган сыннар исеме.
2. Сары төстәге кыйммәтле металл.
3. Мөселманнарның кыйбласы булган изге бина.
4. Ир-атларга гына хас зиннәт.
5. Иген сабагының бөртекле өлеше.
6. Киемнең тузган яки ертылган урынына сала торган тукыма кисәге.
7. Мәзәкче, акыл иясе, хәким.
8. Бер җепкә тезелеп оча торган күчмә кош исеме.
9. Юкә кабыгыннан үргән аяк киеме.
10. Ит белән пешергән ризык исеме.
11. Танылган шагыйребез, хикмәт иясе.
12. Җырларда җырлана торган тау исеме.
13. Кыш көне генә була торган ак бөртекләр.
14. Гарәп язуы белән матурлап нәкышләнгән куак исеме.
15. Җиләкләре тәмле булган чәнчкеле куак исеме.
16. Зәкәрия пәйгамбәрнең улы - бөек нәби. (Кире яктан укырга).
17. Җир вә күкләрне һәм һәммәбезне бар иткән Илаһыбыз.
18. Берәр эш белән кәсеп иткән кеше.
19. Тәмлеткечләр салган томат исеме.
20. Кызларда һәм каеннарда була торган зиннәтләнү әйбере.
21. Бала сүзнең икенче өлеше.
22. Госманлы дәүләтенең башкаласы (Астан өскә таба укырга).

## АЛЛАҺ

*Җир вә күкләр бар иткән,*
*Зур агачлар калкыткан,*
*Гөл-чәчәкләр балкыткан,*
*Бер Аллаһтыр, бер Аллаһ.*
*Мин Аллаһны сөямен,*
*Әмеренә баш иямен.*

*Ашата һәр хайванны,*
*Яшәтә һәр инсанны,*
*Саклый кем бу ватанны,*
*Бер Аллаһтыр, бер Аллаһ.*
*Мин Аллаһны сөямен,*
*Әмеренә баш иямен.*

*Аллаһ һәркайда хәзер,*
*Ни эшләсәм дә күрер.*
*Ни сөйләсәм ишетер.*
*Бардыр, бердер, бөектер.*
*Мин Аллаһны сөямен,*
*Әмеренә баш иямен.*